**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлеге Шунак торак пунктында гражданнар җыены карары**

21.11.2019 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенең Шунак торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлардан кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Бохарай авыл җирлегенең Шунак авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

- торак пункт эчендә мәгълүмат стенды сатып алу һәм урнаштыру;
- зиратка мәгълүмат стенды сатып алу һәм урнаштыру;
- урам яктырткычларын светодиодлы лампочкаларга алыштыру һәм ремонтлау;
- торак пункт эчендәге юлларга вак таш җәю.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бохарай авыл җирлеге башлыгы Р.И. Нуриев